**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3187**
**20.04.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 24 мартындагы 1591 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2022 елның 24 мартындагы 1591 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына, түбәндәге эчтәлектәге 13.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13.1 | Энтузиасты бульвары, 18 йорт «Top hop» кафесы | Җәйге веранда (27 кв.м.) | Җәмәгать туклануы хезмәтләре | 470841,95 2324348,5<br>470845,08 2324351,74<br>470840,78 2324355,92<br>470837,65 2324352,69<br>470841,95 2324348,5 |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов